СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 24 » апрель 2018 ел** **№ 174**

**Арча район Советының 2016 елның 12 июлендәге 64 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 02 декабрендәге ПУ-1042 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы Указы нигезләмәләрен исәпкә алып, Арча район Советы карар бирде:

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Арча район Советының 2016 елның 12 июлендәге 64 номерлы «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи үз-үзләрен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Комиссия турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 3.2.6 пункт өстәргә:

«3.2.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3 һәм 3.2.4 пунктларында каралган мотивлаштырылган бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә уведомлениеләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3, 3.11.1 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм мөрәҗәгатьләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча нигезле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3, 3.11.1 пунктларында яисә башка карарда карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр.».

2) «а» пунктчасының 2 һәм 4 абзацларын, 4.1 пунктындагы «б» пунктчасының 2 абзацын үз көчләрен югалткан дип танырга;

3) 4.2 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән гариза Арча муниципаль районы башлыгы исеменә тапшырыла.»;

4) 4.2 пунктының өченче абзацында «гаризалар һәм мөрәҗәгатьләр» сүзләрен «гаризалар һәм хәбәрнамәләр» сүзләренә алмаштырырга;

5) 4.9 пунктының беренче абзацында «икенче һәм өченче абзацлар» сүзләрен «өченче абзац» сүзләренә алмаштырырга;

6) 4.10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

7) 4.11 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

8) 4.14.1 пунктының беренче абзацында «гаризалар, мөрәҗәгатьләр» сүзләрен «гаризалар, хәбәрнамәләр» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Район Советы рәисе И.Г.Нуриев